# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в статьи 11 и 13 Закона Республики Татарстан «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» и Закон Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в области организации дорожного движения в Республике Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
9 октября 2024 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 3 августа 2009 года № 43-ЗРТ «Об автомобильных дорогах и о дорожной деятельности на территории Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2011, № 4 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 4 (I часть); 2015, № 4, № 10 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 29 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 94 (часть I); 2021, № 77 (часть I); 2022, № 34 (часть I), № 49 (часть I); 2023, № 35 (часть I), № 48 (часть I), № 73 (часть I); 2024, № 28 (часть I) следующие изменения:

1) пункт 7 статьи 11 дополнить словами «, автомобильных дорогах общего пользования местного значения»;

2) в пункте 5 статьи 13 слова «, за пользование на платной основе парковками (парковочными местами), расположенными на автомобильных дорогах общего пользования местного значения» исключить.

**Статья 2**

Внести в Закон Республики Татарстан от 20 декабря 2018 года № 103-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в области организации дорожного движения в Республике Татарстан» (Собрание законодательства Республики Татарстан, 2019, № 2 (часть I); 2020, № 51 (часть I); 2021, № 77 (часть I) следующие изменения:

1) в статье 4:

а) в части 1:

пункт 4 признать утратившим силу;

в пункте 5 слова «в соответствии с предусмотренными пунктом 14 части 1 статьи 5 Федерального закона методическими рекомендациями» исключить;

пункт 6 дополнить словами «, изменений в указанные проекты организации дорожного движения»;

пункт 7 дополнить словами «, изменения в такие утвержденные комплексные схемы организации дорожного движения»;

дополнить пунктами $7^1$ и $7^2$ следующего содержания:

«$7^1$) установление в соответствии с частью $9^3$ статьи 18 Федерального закона порядка разработки, согласования с органами и организациями, указанными в пункте 2 части 8, пунктах 2 и 3 части 9, пунктах 2 и 3 части $9^1$ статьи 18 Федерального закона, и утверждения проектов организации дорожного движения для автомобильных дорог регионального, межмуниципального, местного значения, для частных автомобильных дорог, изменений в указанные проекты организации дорожного движения;

$7^2$) установление в соответствии с частью $9^1$ статьи 17 Федерального закона порядка разработки, согласования с органами и организациями, указанными в пунктах 1, 2 и 4 части 9 статьи 17 Федерального закона, и утверждения комплексных схем организации дорожного движения, изменений в утвержденные комплексные схемы организации дорожного движения;»;

б) в части 2:

пункты 1 и 2 изложить в следующей редакции:

«1) организация дорожного движения на автомобильных дорогах регионального или межмуниципального значения, в том числе мониторинг дорожного движения;

2) обеспечение установки, замены, демонтажа и содержания технических средств организации дорожного движения на автомобильных дорогах регионального или межмуниципального значения;»;

пункт 5 дополнить словами «, изменений в указанные проекты организации дорожного движения»;

дополнить пунктами $5^1$ – $5^3$ следующего содержания:

«$5^1$) согласование проектов организации дорожного движения, разрабатываемых для автомобильных дорог местного значения либо их участков, для иных автомобильных дорог либо их участков, расположенных в границах муниципального образования, изменений в указанные проекты организации дорожного движения в случае, если автомобильные дороги местного значения либо их участки, иные автомобильные дороги либо их участки, расположенные в границах муниципального образования, примыкают к автомобильным дорогам регионального или межмуниципального значения;

$5^2$) согласование проектов организации дорожного движения для частных автомобильных дорог либо их участков, изменений в указанные проекты организации дорожного движения в случае, если частные автомобильные дороги либо их участки примыкают к автомобильным дорогам регионального или межмуниципального значения или пересекают их;

$5^3$) согласование комплексных схем организации дорожного движения, разрабатываемых для муниципального района, городского округа или городского поселения либо их частей, а также для территорий нескольких муниципальных районов, городских округов или городских поселений, имеющих общую границу, изменений в такие утвержденные комплексные схемы организации дорожного движения;»;

2) в части 1 статьи 5:

а) пункты 1 – 3 изложить в следующей редакции:

«1) организация дорожного движения на автомобильных дорогах общего пользования местного значения, в том числе мониторинг дорожного движения;

2) ведение реестра парковок общего пользования, расположенных на территориях соответственно муниципальных районов (в границах сельских поселений), городских округов и городских поселений, за исключением парковок общего пользования, расположенных на автомобильных дорогах регионального или межмуниципального значения;

3) обеспечение установки, замены, демонтажа и содержания технических средств организации дорожного движения на автомобильных дорогах общего пользования местного значения;»;

б) дополнить пунктами $3^1$ – $3^4$ следующего содержания:

«$3^1$) обеспечение разработки комплексных схем организации дорожного движения для муниципального образования, внесения в них изменений, а также утверждение комплексных схем организации дорожного движения и внесенных в них изменений;

$3^2$) установление перечня органов и организаций, с которыми подлежат согласованию проекты организации дорожного движения, разрабатываемые для автомобильных дорог местного значения либо их участков, для иных автомобильных дорог либо их участков, расположенных в границах муниципального образования, изменения в указанные проекты организации дорожного движения;

$3^3$) утверждение в соответствии с частью 9 статьи 18 Федерального закона проектов организации дорожного движения, разрабатываемых для автомобильных дорог местного значения либо их участков, для иных автомобильных дорог либо их участков, расположенных в границах муниципального образования, изменений в указанные проекты организации дорожного движения;

$3^{4}$) согласование проектов организации дорожного движения для частных автомобильных дорог либо их участков, изменений в указанные проекты организации дорожного движения в случае, если частные автомобильные дороги либо их участки примыкают к автомобильным дорогам местного значения или пересекают их;»;

3) в статье 6:

а) часть 1 дополнить пунктом 9 следующего содержания:

«9) создание условий для использования электромобилей и гибридных автомобилей.»;

б) часть 4 после слов «движения велосипедистов,» дополнить словами «электромобилей и гибридных автомобилей, в том числе зарядной инфраструктуры для таких транспортных средств,».

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 марта 2025 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
17 октября 2024 года
№ 84-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 9 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2023, № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 7 пунктында «Региональ әһәмияттәге автомобиль юлларында» сүзләреннән соң «, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында» сүзләрен өстәргә;

2) 13 статьяның 5 пунктында «, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдалану» сүзләрен төшереп калдырырга.

## 2 статья

«Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2018 елның 20 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяда:

а) 1 өлештә:

4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктта «Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган методик рекомендацияләр нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «оештыру проектларын» сүзләреннән соң «, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта «комплекслы схемалары» сүзләреннән соң «, расланган шундый юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларына үзгәрешләр» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ һәм $7^2$ пунктлар өстәргә:

«$7^1$) Федераль законның 18 статьясындагы $9^3$ өлеше нигезендә региональ, муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары өчен, хосусый автомобиль юллары өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне эшләү, Федераль законның 18 статьясындагы 8 өлешенең 2 пунктында, 9 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында, $9^1$ өлешенең 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибен билгеләү;

$7^2$) Федераль законның 17 статьясындагы $9^1$ өлеше нигезендә юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, расланган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларына үзгәрешләрне эшләү, Федераль законның 17 статьясындагы 9 өлешенең 1, 2 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән органнар һәм оешмалар белән килештерү һәм раслау тәртибен билгеләү;»;

б) 2 өлештә:

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру, шул исәптән юл хәрәкәтен мониторинглау;

2) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыруны, алмаштыруны, сүтүне һәм карап тотуны тәэмин итү;»;

5 пунктта «оештыру проектларын» сүзләреннән соң «, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ – $5^3$ пунктлар өстәргә:

«$5^1$) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан башка автомобиль юллары йә аларның өлешләре региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына кушылган очракта җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан башка автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне килештерү;

$5^{2}$) хосусый автомобиль юллары йә аларның өлешләре региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына кушылган яисә аларны кисеп үткән очракта хосусый автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне килештерү;

$5^{3}$) муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге йә аларның өлешләре өчен, шулай ук уртак чикләре булган берничә муниципаль район, шәһәр округы яисә шәһәр җирлеге территорияләре өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, расланган шундый юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларына үзгәрешләрне килештерү;»;

2) 5 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 – 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыру, шул исәптән юл хәрәкәтен мониторинглау;

2) региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан тыш, тиешенчә муниципаль районнар (авыл җирлекләре чикләрендә), шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре территорияләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы парковкалар реестрын алып бару;

3) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын урнаштыруны, алмаштыруны, сүтүне һәм карап тотуны тәэмин итү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $3^{1}$ – $3^{4}$ пунктлар өстәргә:

«$3^{1}$) муниципаль берәмлек өчен юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын, аларга үзгәрешләр кертүне эшләүне, шулай ук юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын һәм аларга кертелгән үзгәрешләрне раслауны тәэмин итү;

$3^{2}$) җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан башка автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен эшләнә торган юл хәрәкәтен оештыру проектлары, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләр килештерелергә тиешле органнар һәм оешмалар исемлеген билгеләү;

$3^{3}$) Федераль законның 18 статьясындагы 9 өлеше нигезендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен, муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан башка автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне раслау;

$3^{4}$) хосусый автомобиль юллары йә аларның өлешләре җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына кушылган яисә аларны кисеп үткән очракта хосусый автомобиль юллары йә аларның өлешләре өчен юл хәрәкәтен оештыру проектларын, күрсәтелгән юл хәрәкәтен оештыру проектларына үзгәрешләрне килештерү;»;

3) 6 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) электромобильләрдән һәм гибрид автомобильләрдән файдалану өчен шартлар тудыру.»;

б) 4 өлештә «велосипедта йөрүчеләрнең хәрәкәтен тәэмин итү максатларында инфраструктураны үстерү» сүзләрен «велосипедта йөрүчеләрнең, электромобильләрнең һәм гибрид автомобильләрнең хәрәкәтен тәэмин итү максатларында инфраструктураны, шул исәптән мондый транспорт чаралары өчен заряд җыю инфраструктурасын үстерү» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 17 октябрь
№ 84-ТРЗ